**Татарстан Республикасы Телэче районы Югары Кибэхуҗа урта мэктэбе**

# «Һаман да истә»

**Тозеде: Педагогр – организатор**
**Гинатуллина Гульчачак Наилевна**

**А.Б.** Кырда иген чайкала, иген чайкала...

Бу – елына бер генә тапкыр килә торган атна. Ул атнада көннәр эссе дә, болытлы да булмый: кырда ниндидер зәңгәр дулкын йөгерә, арыш басуы яшелле-күкле булып сөрем эчендә кайный. Көр басуның шулай дулкынлануына карап торуы рәхәт тә, моңсу да. Менә җәйнең иң кыска төннәре җитте, моннан соң инде төн кыскара башлар. Арыш басуы саргаер, ул инде дулкынланмас. Аны урып алырлар, борчак җиреннән кайтышлый ял итәргә чүмәләләр арасына торналар төшәр. Көз җитәр... Һай, бу гомернең бәрәкәтсезлеге. Әле генә бит, әле сабан тургайлары яшел уҗым өстендә ук булып атылып сайрыйлар иде. Ә хәзер – арыш басуы өстеннән җил йөгерә - сагыш арта...

Бүген 1941 елнын 21 июнь киче. Бары да шулай калыр кебек, тик офыкта баткан кояш кына артык кызыл, никтер шомлы буген , гүя әйтә сыман: эх, уйнагыз, көлегез, өйләрегезгә кайтып татлы төшләр күреп йоклагыз! Бу Сезнең тыныч үткәргән соңгы кичегез, адәм балалары! Иртәгә атасы таң сезгә куп сынаулар, кара хәсрәт алып килер, нык булыгыз.

***Левитан тавышы***
***Радиодан “Священная война” җыры ишетелә***

**А.Б.** Соңгы тапкыр кичә көлде дөнья
Соңгы тапкыр кояш баеды.
Таң атмады бүген,көн тумады
Алды җирне сугыш ялкыны.

***Кич белән урам әйләнү җырлап, гармун белән.***

***1. Сугышка озату күренеше.*** *Барлык катнашучылар сугышка китүчеләрне озатырга чыгалар (Илгиз, Альберт абый, Әсгать, Радиль, Рәхимҗан абый, Рания, Лидия, Рәмзинә, Гөлназ, Г.Гөлназ) Гармун тавышлары.*

***Илгиз:*** Ярманда машина күп җәмәгать, аллага тапшырдык. Батырлыкка безнең халыкка чыкмый чыгуын, иллә мәгәр тегеләрдә корал таза. Аларның карчыклары да базарга барганда бисәпилкегә генә утырып чабалар. Уйнама син алар белән...

***Әсгать:*** Ни өчен бу вакытта соң бу сугыш, Сабантуй да итеп булмады бит. Аннан печәнгә төшәсе, игеннәрне урып-җыясы бар иде. Ни өчен шулай вакытсыз башланды? Ничек инде ул шундый кызу эш вакытында сугыш башлыйлар? Башында мие бармы бу германнарның? Ичмаса, морҗа чыгарганны гына көткән булалар...

***Хәмит*** : - Җәмәгать! Җәмәгать! - *гармун тавышлары тына,* Җәмәгать! Мин сезгә менә нәрсә әйтмәкче булам. Бәхил булыгыз туганнар, дуслар... Без кая барганыбызны беләбез. Безгә кайтулар булмас инде. Әйе, кайтулар – едвали. Герман армиясе бик кабәхәт армия ул. Безгә кайтулар - едвали. Бәхил булыгыз. Тату яшәгез. Миңа үпкәләүчеләр бардыр арагызда. Заманында җир селкетеп йөрдек. Үпкә-сапкагыз булса – онытыгыз. Безгә кайтулар булмас инде. Әйе, едвали...

***Альберт абый: :*** Иптәшләр, бу сугыш канлы, корбанлы булыр. Ә сез җебеп төшмәгез. Колхозны үзебез төзедек, шуны саклагыз. Бер-берегезгә ярдәмле булыгыз. Дөрес, безнең барыбыз да кайта алмас. Ләкин кайткан кешеләр алдында кызарырлык булмагыз. Сау булыгыз, әгәр, председатель буларак, ачуыгызны китергән чакларым булган икән – гафу итегез. Колхозны аяктан екмагыз, иптәшләр, сау булыгыз…

**Зөләйха** (*Г.Гөлназ) Радильгә кулъяулык бирә*:- менә жаным истәлегем булсын.
**Хафаса** *(Гөлназ)*- улым, элекедән килгән гадәт, ипи капсанчы, ә мин аны үзең кайтышка саклармын балам (*ипи каба )*
***Мирсәлим***: Елама, әнкәй, йә герой булып кайтырмын, йә герой булып үләрмен. Сау бул, әнкәй. Сау бул, сөйгәнем.
*Җырлап әйтә:* Без китәрбез ахырылай
Чуен юллар аркылы шул,
Чуен юллар аркылы.
Өстемдәге ак күлмәгем
Кәфен булыр, ахры.

***Әсгать***: Эх, шулай җырлыйлар димени *(җырлый) ”Герман көе”*
*Җырның ахыргы куплетында барысы да җырлап, гармун тавышына кушылып озата чыгалар.*

**А.Б.** Бетмәс-төкәнмәс мәшәкатләре белән авылда сугыш чоры тормышы башланды... Сугыш җан өшеткеч бер хәл икән. Авыл халкы гомер буе җыр белән көн иткән булса, инде җыр тукталды... Ләкин күңелдәге моң-сагышны, сагынуны кая куясың?

***Алия җырлый “Җиңеп кайт”***

**2.** ***Аулак өй күренеше****. Хатын-кызлар сугышка җибәрү өчен оекбашлар бәйлиләр. Җырлыйлар. Солдат хатлары уку.*
***Хафаса карчык*** Минем улымның командирыннан хат килде. Әби, дигән иде командир, бик батыр ул үстергәнсез, командование сиңа кат-кат рәхмәт укый, андый егетләр белән бу сугышта без һичшиксез юлбасарларны дөмектерәчәкбез, дигән.
***Рания:*** Минем Мәгъдәнемнән дә хат килгән иде әле, хатында каты бәрелешкә керәбез, дошманны шунда пыр туздырачакбыз да җиңеп кайтачакбыз, дигән. Һаман да шул тракторы белән җеннәнә, бер генә подшипнигы югалып карасын, матри аны хатын, кайткач күрмәгәнеңне күрсәтермен дигән.
***Хәнифә:*** Сугышын да әйтер идем инде, шул тикле озакка бармаса... Шулай безгә каршы торырлык дәрәҗәдә көчле микәнни ул немецлар, нигә тизрәк бөтереп тыкмыйлар икән шуларны?... Ә алар безнең авылның байтак кешесен харап иттеләр бит инде. Әле бер көнне генә килен белән санап утырган идек, авылыбыздагы шул нибары утыз җиде йорттан кырык өч кеше сугышка киткән. Шуларның егерме тугызы турында я “үлде”, яки “хәбәрсез” югалды

дигән язу килгән дә инде. Әгәр шушылай барса, безнең авылның бер кешесе дә кайтмаячак бит! Килен әйтә, әле һаман фашистлар безне кысрыклый, ди. Белмим, ни белән бетәр икән моның ахыры!...

***Рания*** Әйдәгез әле, нигә һаман моңаеп утырабыз соң, кызым кил әле, бер матур җырыңны җырлап күрсәт әле безгә. Йөрәкләргә ял булмасмы, ичмасам. *(өзгәләнеп әйтә).*

***Рания җырлый***

***Хафаса карчык*** И. Һаман утырабыз да, утырабыз, соң икән бит инде, ятарга вакыт, әйдәгез. *Чыгып китәләр.*

**А.Б.** Гөрләгән су буйлары тынып калды. Шыксыз көз җитте. Сугыш башланганнан бирле болай да бушап калган авылдан сәламәтрәк кешеләрне окоп казырга җибәрделәр. Кая ул җыр, кая сиңа уен! Егетләр сугышта, кызлар урман эшендә, окопта. Авылның тыны кысылды. Хәсрәт, сагыш эчкә җыелды. Бер ел үтте, ике ел... Әле сугышның очы-кырые күренми. Менә бөтен матурлыгы белән кырык өченче елның июне җитте. Шул ук таңнар, шул ук сандугачлар, су буенда шул ук чыңлы үлән, түгәрәк уен уйный торган урын. Менә бер кичне монда дүрт-биш кыз төште. Икенче көнне – күбрәк. Баксаң, ике ел эчендә авылда ике оя кызлар өлгергән икән. Ике оя малайлар үсеп житкән икән... Һәм түгәрәк уеннар башланды. Чү, ишетәсезме, әнә үзләре дә килә түгелме.

***Кичке уеннар күренеше.*** *"Каз канаты" биюе. Бию беткәннән соң кызлар түгәрәк уенына басалар. Егетләр уенга катнашмыйча читтә басып торалар. Бер кыз уенга кермичә басып торган егетләргә ишарәләп:* И, адәм мәсхәрәләре, үзләренә күрә түгел, уенга кермичә авыз ерып басып торалар. Сугыштагы егетләр кайтса бураныгызны уйнатырлар иде! Әйдәгез, әйдә, кушылыгыз. *Барысы да уенга кушылып китәләр.*

*Уен беткәч Гөлназ керә:* Әйдәгез, кайтыйк инде, иртүк торасы да бар, печәнгә төшәсе. *Барысы да кушылып, әйдәгез, әйдәгез дип таралышалар.*

***Г.Гөлназ җырлый.***

**А.Б.** Фашист окупантлары илебезнең бик күп кенә шәһәр, авылларын юк иттеләр. Ләкин совет халкы дошманны җиңү өчен барысын да эшләде. Фронттагылар соңгы сулышларына кадәр көрәштеләр.

Ул кабатлап,лачын йөрәгенең
Изге антын сөйгән халкына
Автоматын асты аркасына
Һәм атланды акбүз атына.
Егет үткән юлда сафлар сынды
Туплар ауды,танк ватылды.
Кайдан алды егет мондый көчне
Кайдан алды мондый ялкынны.
Байрак итеп илгә турылыкны
Утны-суны кичте бу егет
Автоматы түгел,аты түгел
Анты белән көчле бу егет.

***Сугыш вакыты күренеше. С****олдатлар ял итеп утыра, кайсы хат язып утыра, кайсы тәмәке төрә, бер солдат газета укый.. (Әсгать, Алберт абый, Илгиз, Рәхимҗан абый, Фәнил) Бер кырыйда гармунга кушылып* ***Әсгать җырлый: “Сагынам дуслар” (кушылып җырлыйлар)***

*Җыр беткәч* ***Илгиз кердә:*** “Ягез әле, газетаның соңгы санында үзегез турындагы хәбәрне укып күрсәтимме?”

«...150 гә каршы — 5. Автоматлар белән коралланган 150 гитлерчы,, ярым божра рәвешендә тезелеп, безнең батареяның күзәтү пунктына таба ыргылды. Бу вакытта пунктта биш сугышчыбыз була. Егетләр хәлнең бик җитди икәнен аңлыйлар, әмма сынатмыйлар. Пулеметчы Садриевның куәтле уты мактанчык фашистларны кыра бирә. Гитлерчылар, югалтулары белән исәпләшмичә, безнең биш героебызга якынаюларын дәвам иттерәләр. Садриев яралана. Аны Бычков алыштыра. Ул да яралана. Ярасын бәйләгән Садриев тагын пулеметны үз кулына ала. Ул икенче тапкыр яралана һәм дөнья куя. Пулеметка Редько тотына. Шул чак бу батырларга ярдәмгә безнең солдатларның-икенче төркеме килеп җитә. Күзәтү пункты саклап калына. Фашистлар җиңелә...»

***Алберт абый:*** Безнең арада тагын бер герой бар бит әле. *(Радильгә күрсәтеп)* Менә ичмасам герой дисәң дә герой! Молодец .булдырдың!

***Радиль***: Карале, иптәш, син минем турыда газетага язарга булдыңмы әллә?

***Илгиз***: Әйе, менә тагын язмыйча, геройларыбызны халык белергә тиеш.

***Радиль***: Ярар, минем турыда язсаң язарсың, тик менә Зөләйха исемле акыллы да, чибәр дә кәләшем барлыгын, аның миңа хатлар язып торуын телгә алма. Килештекме? Югыйсә ул, белә калса, мин аның мәхәббәте белән мактанып, бөтен кешегә сөйләп йөрим икән дип уйлар да үпкәләр. Менә эт җан Гитлерның муенын боргач өйгә кайтып өйләнеп җибәрермен, балаларыбыз булыр, шунда рәхим итеп килерсең дә җаның теләгәнчә язарсың. Ә хәзергә әле бу – сер.

***Барысы да көлеп җибәрә***.

***Алберт абый:*** Шундый күркәм кәләшең барлыгын яшереп торалар димени? Аның турында язарга кирәк, белеп торсыннар.

***Радиль:*** Алайса, әлегә русча язып тор, ә үзебезчә соңыннан язарсың. Зөләйха белән яратышканыбызны авылныкылар хәзергә белми торсыннар әле.

***Әйдә алайса диешеп Илгиз, Радиль чыгып китәләр.***

***Фәнил:*** *Мәктәп вакытларын искә төшерә:*

***5 класс татар халык биюе. Ансамбль җыры.***

***Илгиз кердә:***Менә сез кайда утырасыз икән, сезне штабка чакыралар. *Барысы да чыгып китәләр.* ***Илгиз кала, җырлый.***.

**А.Б.** Солдат хатыннары! Аларның тормышлары михнәтле, тамаклары ачлы-туклы, күңелләре тулы сагыну иде. Эшенә, ачлыгына түзәр идең, хатыннарны тол, бала-чагаларны ятим итеп авылга туктаусыз кара печатьле кәгазьләр агылды. Эх, ул кара печатьле кәгазьләр, еллар үтсә дә бәгырьне телгәлиләр. Ничек инде аның газизе генә үлсен дә, аның газизе генә хәбәрсез югалсын ди, хәбәрсез югалырга, ул бит кеше, адәм баласы.

***Мөнәвәрә апа “Хәбәрсез югалганнар”***

***Сәхнәгә Дилбәр белән Тәлгать чыга.***

Дилбәр. Саумысыз!

Тәлгать. Саумысыз, Дилбәр. Утырыгыз.

Дилбәр *(утырып).* Рәхмәт. Тик мин озакка түгел — кызым бер үзе калды.

Тәлгать. Мин иртәгә таң белән китәм.

Дилбәр. Ишеттем. Юлыгыз хәерле булсын.

Тәлгать. Рәхмәт. Киткәнче, сезнең белән сөйләшер сүзем бар иде.

Дилбәр. Гөлнар шулай диде.

Тәлгать *(сүз таба алмый тора).* Теге... теге көндә мин сезне бик нык рәнҗеттем.

Дилбәр. Әйе.

Тәлгать. Исерек идем, дип акланырга теләмим. Бөтенесе дә хәтеремдә... Мин сезнең янга фронтташ дустымның соңгы үтенече белән килдем... Тик шуның өчен... Ләкин сезне күрү... еллар буена тупасланып беткән йөрәгемне кинәт эретеп җибәрде... Бер юлы ташып чыккан хисләремне йөгәнли алмадым...

Дилбәр. Шулай инде... Ялгыз хатын — ялгыз каен. Теләсә кайсы яктан искән җил башта аңа кагылып уза. Ярый да ул таң алдыннан искән йомшак җилләр генә булса... Аның бит үзәкләреңә үтеп туңдыра торган көзге әче җилләре дә бар. Каеннарны гына түгел, хәттә имәннәрне җиргә тиклем бөгә торган давыллары да бар. *(Өч каенга күрсәтеп.)* Аларга җиңел, бер-берсенә таяналар. Ә ялгыз каенның таянычы юк, аның аянычы гына бар. Шуның өчен аларны рәнҗетмәгез.

Тәлгать. Мин гәепле... Тик яман ният белән дип уйламагыз, зинһар?

Дилбәр. Сез дә ялгыз хатыннар турында ялгыш фикер белән китмәгез. Алар үзләре теләп ялгыз яшәми. Көттерүгә караганда, көтүе газаплырак. Ә «үлде» дигәндә көтүе — икеләтә...

Тәлгать. Аңлыйм...

Дилбәр. Ю-к, сез аңламыйсыз аны. Без дә җанлы кешеләр. Безнең дә иркәләнәсебез, иркәлисебез килә. Шундый чакларда сез сукыр дип атаган өметтән башка нәрсәбез юк безнең. Шул өметкә табынабыз. Ә ул иркәләми, йөрәге җылы булса да, куены салкын.

Тәлгать. Барысы өчен дә гафу итегез, Дилбәр.

Дилбәр. Гафу үтенмәгез. Мин ирләрнең гафу үтенүләрен яратмыйм.

Тәлгать. Алайса, минем хакта начар уйда калмагыз.

Дилбәр. Юк. Сез начар кеше түгелдер. Үз бәхетегезне табарсыз. Әгәр дөньяда Мәгъдән булмаса, бәлки, мин дә яраткан булыр идем... Башта күргәч тә, «соңгы өметемне үтерергә килгәндер бу», дип курыккан идем. Хәзер... курыкмыйм...

Тәлгать. Димәк, өметегез җиңде?

Дилбәр. Җиңде.

Тәлгать. Көтәсез?

Дилбәр. Көтәм.

Тәлгать. Ә сугыш бетүенә ике ел...

Дилбәр. Әйе, ике ел... Минем, сугыш беткәч, биш ел көтәргә дигән вагъдәм бар.

Тәлгать. Биш елдан соң?

Дилбәр. Ун ел көтәргә.

Тәлгать. Уннан?

Дилбәр. Уннан... гомергә... үлгәнче. *(Өч каенга карап.)* Мәгъдән бу каеннарның берсен — үзенә, берсен — миңа, берсен - кызыбызга охшата торган иде... Киткәндә шушы юлдан китте... Кызымны күтәреп шушында озатып калдым... Ул шушы юлдан кайтып төшәргә тиеш... Мин көн дә аны каршы алырга киләм... *(Тирән көрсенеп.)* Ул минем ничек көткәнемне генә белми. Әгәр белсә, кабереннән торып кайтыр иде! *(Урыныннан торып.)* Ярый, мин кайтыйм. *(Тәлгатькә кулын биреп.)* Хушыгыз!

Тәлгать. Хушыгыз!

*Дилбәр китә башлый.*

Дилбәр!

Дилбәр *(борылып)*. Нәрсә?

Тәлгать *(китель кесәсеннән нидер алып бирергә тели, ләкин кире уйлый)*. Юк, бер нәрсә дә юк.

*Дилбәр чыгып китә. Тәлгать аны күз карашлары белән озата да эскәмиягә килеп утыра, китель кесәсеннән әле Дилбәргә бирергә уйлаган фотосүрәтне чыгара.*

*(Фотога озак кына карап утыра, аннан әйләндереп укый.)* «Мәгъдән! Минем бу фотомны үзең үлгәч кенә кире кайтарырсың, яме? Синең Дилбәрең. 1939 ел». *(Пауза. Ул фотоны кесәсенә салып куя, йөри.)* Ни эшләргә соң? Барысын да язмыш кочагына ташлап, тыныч кына китеп барыргамы? Әллә... әллә...

***Фәнил җырлый.***

**А.Б.** Төннәрен урам тын була, утлар сүндерелә. Соңгы төннәрдә Фәхерниса карчыкның гына тонык ут яктысы күренә. Кышның шул зәһәр көннәрендә аның карап торган бер улының үлгән хәбәре килде. Күрше авылы егете: “Мирсәлимне үз кулым белән җирләдем, немец минасына шартлап харап булды, әнисенә әйтегез” – дип язган иде. Шул хат килгән көнне Фәхерниса карчыкка кара печатьле кәгазь дә килеп төште. Шуннан соң аның йокысы качты, гел төнлә белән улы кайтып кергән кебек була: капка-койма шыгырдап алса да, салкыннан өй бүрәнәсе шартласа да ул күзен ача, ишеккә озак карап тора, тик улы гына юк.... Ана улы белән хыялында күрешә, сөйләшә башлады.

**5. *Солдат белән ана күренеше.***

Хафаса. Кырык беренче елның май башында шалун-шалун кызыләрмис китә көнбатышка таба... Сүземне шулай башласам, кеше көлгән була. Белми алар: бу бит минем

сүземнең дә, эшемнең дә биемилласы. Шуннан башка кулыма эш бармый, юлым уңмый... Ә мин хәзер озын юлга чыктым, улым, Мирсәлимем янына барам.

***Радиль җырлый “Сагыну”***

Хафаса. Мирсәлим балакаем, бу син бит.

Солдат. Мин, әнкәй... Әллә улыңны танымый торасыңмы?

Хафаса. Соң ни... Сине карарга вакыт булдымыни әле. Килә бит газраил, аны, атмый, туктатып буламыни.

Солдат. Була, әнкәй. Мин туктасам, алар да туктый.

Хафаса. Сөбханалла. Ә нигә алай...

Солдат. Бу бит, әнкәй, әллә кайчан булып үткән хәл. Ул танклар күптән җимерек, аларның корычын яңадан койдылар, корычтан күпер төзеделәр, һәм син шул күпер аша чыгып, минем яныма килдең.

Хафаса. Ә син үзең?

Солдат. Минме! Мин үлмәсәм, ул танклар җимерелмәс иде, әнкәй.

Хафаса. Шулай шул. Алайса ни, без утырып сөйләшә алабызмы синең белән?

Солдат. Туйганчы сөйләшәбез, әнкәй.

Хафаса. Мин сине кочаклый да аламмы?

Солдат. Кочакла, әнкәй.

Хафаса. Башыкаең җып-җылы бит.

Солдат. Синең кулларың тигән өчен ул, әнкәй.

Хафаса. Шулай тын гына утырыйкчы... Син ял ит, арыгансыңдыр... Теләсәң, җыр җырлармын үзеңә. Утыз ел буе көттем сине. Башта хәбәрсез югалган, диделәр. Ышанмадым, хәбәрсез югалырга, син төшеп калган бияләймени. Бияләй дигәннән, һәр елны өч пар бияләй бәйлим, көз киярсең, кыш киярсең, яз киярсең дип. Сине көтәм-көтәм дә бияләйләрне Гыйлмиярга илтәм.

Солдат Гыйлмияр? Фарукша улымы?.. Художникка укыган малай..

Хафаса. Малай түгел. Аңа хәзер илле яшь тулып узды. Гел генә буяулар белән булаша, художниктыр, маляр дип йөртәләр, гарип ул. Куллары гарип... Ярар, көткән — морадына җиткән. Мин дә көтеп алдым хәбәреңне. Күрсәткән батырлыгың өчен орденың килде — үзеңә биримме?

Солдат. Миңа аның кирәге юк инде. Үзеңә булсын. Килешеп тора.

Хафаса. Сафура белән Шәфига да, килешә, диделәр шул.

Солдат. Алар исән-саулармы?

Хафаса. Исән-сау, улым, җимертеп дөнья көтәләр. Мине читләтмиләр, алар учагында миңа да җылы.

Солдат. Үз учагың юкмыни?

Хафаса. Бар, бар, улым. Алай дигәч тә... Дөньям бөтен.Совет исән булса, колхоз исән булса, безнең кебекләрнең дөньясы бөтен булыр әле, иншалла. Ел да суйган сугымнан сиңа өлеш калдырам... Сине белгән- күргән кешеләр килеп керә. Алар сине гел генә яхшылык

белән телгә алалар, рәхәт була күңелемә.

Солдат. Әнкәй, син Зөләйхәне беләидеңме?

Хафаса. Әй, улыкаем. Ана кеше улының тын алышыннан сизеп тора — эчемнән генә, киленем, дип йөртә идем үзен, китеп бардың бит.

Солдат. Исән-саумы ул?

Хафаса. Исән-имин. Ул да олыгайды, биш бала тәрбияләп үстерде.

Солдат. Сәлам әйт аңа миннән. Ара-тирә исенә төшерсен мине, хәтерләсен. Безгә хәзер бер нәрсә дә кирәкми бит.

Хафаса. Әйтермен, улым, бәйнә-бәйнә әйтермен. Ул минем хәлемне белешеп йөри. Әллә кайдан сүз куша: нихәл, Чибәр әби, ди.

Солдат. Чибәр? Сине шулай дип йөртәләрмени?

Хафаса. Исememне күптән оныттым инде мин, улым. Сине шулай өзелеп көткән өчен кешеләр үземне Чибәр дип атады.

Солдат. Рәхмәт кешеләргә. Ә хәзер миңа вакыт... Бәхилләшик тә, син кит инде. Карама, кыен булыр үзеңә соңыннан.

Хафаса. Кума мине, улым. Кыены артта калган инде аның. Әниеңне хәзер бер нәрсә белән дә куркытып булмый. Аналар алар шундый заттан.

Солдат. Фатихаңны бир, әнкәй. Соңгы алышка керәм.

Хафаса. Мирсәлим балакаем! *(Аны кочаклый.)* Бәхил бул, буының калтырамасын дошман алдында, фатихам сиңа шушы.

***Гөлия "Син кайтмадың"***

***6. Сугыштан кайту күренеше.***

***Моңлы итеп «Мөхәммәдия» укый. Бераздан Мөршидә кайта. Хәни-фә әбинең укуын бүлмәс өчен әкрен генә чигенә. Пауза.***

Х ә н и ф ә. Сөбханалла, кайттыңмыни, кызым?

М ө р ш и д ә. Кайттым, әнкәй. Бик моңлы итеп «Мөхәммәдия» укый идең ахры.

Х ә н и ф ә. Карчыкларның шул инде, балам. Күңеле сынды исә, борынгы китапка тотына. Дин китаплары укый дип син миңа ачуланмыйсыңдыр ич?

М ө р ш и д ә. Мин, әнкәй, сиңа беркайчан да ачуланганым юк һәм ачуланмам да. Үзең беләсең, анадан бала вакытымда ук ятим калдым. Ана иркәләвенең нәрсә икәнен белми үстем. Үги ананың да җәберен күп күрергә туры килде миңа. Тик менә сезгә килгәч кенә ана мәхәббәтенең, апа иркәләвенең нәрсә икәнен аңладым.; Син миңа туган анам кебек үк шәфкать күрсәттең. Күрсәткән изгелегеңне бервакытта да онытмам, әнкәй. Мин сине беркайчан да ташламам. Без, әнкәй, башыбызга килгән кайгыны бергә кичерербез. Бергә булгач, нинди генә авырлыкка да түзәрбез. Түзәрбез бит, әнкәй, шулай бит?

Х ә н и ф ә. Елыйсың түгелме, балам? Ни булды, кызым?

М ә р ш и д ә. Хәмитнең иптәшеннән хат алдым...

Х ә н и ф ә. Соң?!.

М ө р ш и д ә. Әнкәй, бәгырем!.. *(Хәнифәне кочаклый.)*

Х ә н и ф ә. Әллә берәр хәл...

М ө р ш и д ә. Әйе, әни, Хәмитебез... *(Әйтеп бетерә алмый, үкереп елый.)*

Х ә н и ф ә. Ярабби! Бу хәбәрне ишеттергәнче, җанымны алган булсаңмы!

М ө р ш и д ә. Ела, әнкәй, тик зинһар үлем турында гына сөйләмә. Без яшибез, яшибез әле... Фашист явызлар ирләребезнең каннары, безнең күз яшьләре өчен җавап бирерләр, ә без яшәрбез.

Х ә н и ф ә. Тик Хәмит балам кайтмас.

М ө р ш и д ә. Әйе, Хәмит кайтмас! Хәмит кебек меңнәрчә ил батырлары туган илләренә кире кайтмас.

Х ә н и ф ә. Мөршидә, кызым!

М ө р ш и д ә. Әү, әнкәй?

Х ә н и ф ә. Бәлки әле исәндер.

М ө р ш и д ә. Язып җибәргән иптәше үзе күргән, әни, исән түгел.

Х ә н и ф ә. Әй, балам, балам...

***Мөршидә сүзсез генә чәй урыны әзерли. Ишек шакыйлар.***

Х ә н и ф ә. Ишектә кеше бар, кызым.

М ө р ш и д ә *(ишеккә килеп).* Кем бар?

Т а в ы ш . Мин, Мөршидә.

М ө р ш и д ә. Кем?

Тавы ш. Мин, Хәмит.

***Мөршидә кабаланып ишекне ача. Култык таягына таянып Х ә м и т керә. Сул кулы бәйләнгән, битендә зур яра эзе. Бар да сүзсез катып кала.***

Х ә н и ф ә. Балам!

М ө р ш и д ә. Хәмит!

Х ә н и ф ә. Синме бу, Хәмит балам!

Х ә м и т *(кочаклап).* Мин, әнкәй, мин! Мөршидә җаным!

***Хәмитне чишендерәләр.***

М ө р ш и д ә. Ә без синең үлүең турында бер иптәшеңнән хат алдык.

Х ә м и т . Хат? Гаҗәп! Кемнән икән ул. Кая, күрсәт әле, күрсәт...

Х ә н и ф ә. Менә бирегә, йомшакка утыр, балам.

Х ә м и т . Ярый, ярый, әнкәй, рәхмәт, борчылма.

М ө р ш и д ә *(китаплар арасыннан хатны эзләп алып).* Менә.

Х ә м и т *(хатка күз йөртеп чыгып).* Фәйзуллин! Исән! Ә мин аның үзен һәлак булды дип уйлаган идем!

Мөршидә. Аңлат, зинһар, ничек булды соң бу?

Х ә м и т . Танкыбыз яна башлагач, сикереп чыкканымны хәтерлим, башкасын хәтерләмим. Аңыма килгәндә караңгы төн иде инде... Туп, мылтык тавышлары каядыр еракта ишетелә. Димәк, безнекеләр күп кенә чигенгәннәр. Бөтен тәнем ут булып яна. Кузгалып карыйм, хәлем юк. Кинәт каршыма нииндидер бер кеше

килеп басты. Кем ул? Дусмы? Әллә дошманмы? Ул, фашистлардан качып, урманга килгән бер кыз булып чыкты. Батыр һәм изге йөрәкле кыз. Мине ул, дошман күзеннән яшереп, ике атна буе тәрбияләде, дәвалады. Мин бераз сәламәтләнгәч, партизаннар янына алып барды.

М ө р ш и д ә . Ә син ничек өйгә кайта алдың соң?

Х ә м и т . Дүрт ай партизаннар белән бергә булдым. Кулымнан килгән кадәр ярдәм иттем. Уңай момент туры килү белән, партизаннар мине фронт аша үзебезнең якка чыгардылар. Шулай итеп, сезгә имгәккә өйгә кайттым.

Х ә н и ф ә. Ой, нигә алай дисең, балам!(елый)

***Мөршидә еламаска тырыша. Ләкин аның күзләреннән мөлдерәп яшьләр тама.***

*Рания йөгереп керә:* Күршеләр, күршеләр, сөенче, сугыш беткән, кайталар, җиңү белән кайталар!

***Шул вакыт радиодан Левитанның сугыш бетүе хакында әйткәне ишетелә. "День Победы" җыры яңгырый. Бөтен катнашучылар сәхнәгә чыга.***

**А.Б.**Тормышның үз законы бар,еш кына яхшылыклар тиз онытыла, ә авырлык, кайгы, хәсрәт хәтердә мәңге кала. Шуның өчендер халкым чиксез булып тоелган бу куркыныч көннәрне бүгенгедәй хәтерли. Җирдә мәңгелек тынычлык булсын өчен миллионнар һәләк була. Шуның өчен дә кайда да булса , сугыш турында ишетсәк, йөрәгебез сыкрый,җаныбыз әрни.

Һәйкәл булып баса җиңүчеләр
Һәйкәл булып баса батырлар
Ә батырлар,ике тапкыр үлми
Җирдә алар мәңге балкырлар.

*Җырлаучы балалар чыгып баса.*

***"Һаман да истә"** музыкасы башлана*

А.Б. Җиңү көнендә бу һәйкәлләргә җан иңәр дә,алар барысы бергә: "Кешеләр,безне онытмагыз" диярләр кебек.Корбан булган ил уллары,безнең хәтердә мәңге сакланыр.

Таш һәйкәлләр балкый тыныч кына,
Өйрәнгәннәр алар тынлыкка.
Һәйкәлләргә килик,гөлләр куйыйк,
Һәйкәлләрне тыңлыйк тын гына.

***Ансамбль җыры: "Һаман да истә".***